Таныштым
Озот

Актаныш муниципаль районы Башлыгына

## Актаныш муниципаль районында 2020 елның беренче ртыеллыгында гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау нәтиҗәләре турында

2020 елның беренче ртыеллыгында муниципаль район Башлыгы һәм Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетына гражданнардан 157 мөрәҗәгать керде, шуларның 40ы интернет-кабул итү һәм электрон почта аша керде.

Гражданнарның муниципаль район Башлыгына һәм Башкарма комитет җитәкчесенә мөрәҗәгатьләренең тематикасы, нигездә, халыкның социаль һәм икътисадый хәленә кагылышлы сораулар: торак шартларын яхшырту, коммуналь-көнкүреш хезмәте күрсәтү, экология, капиталь төзелеш, халыкны социаль яклау, медицина хезмәте күрсәтү, социаль яклау проблемалары.

Барлык кергән мөрәҗәгатьләрне түбәндәге категорияләргә бүлеп бирергә мөмкин:

| № | Гражданнар мөрәҗәгатьләре төрләре | Мөрәҗәгатьләр саны | % |
|---|---|---|---|
| 1 | Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау | 22 | 14% |
| 2 | Икътисад, сәнәгать | 5 | 3,9% |
| 3 | Төзелеш, архитектура һәм торак шартларын яхшырту | 62 | 39,4% |
| 4 | Мәгариф, фән, мәдәният һәм спорт | 16 | 10% |
| 5 | Коммуналь хезмәтләр | 6 | 3,8% |
| 6 | Экология һәм табигый ресурслар | 1 | 0,63% |
| 7 | Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек | 8 | 5% |
| 8 | Законлылыкны тәэмин итү һәм хокук тәртибен саклау | 6 | 3,8% |
| 9 | Дәүләт хакимияте органнары эшчәнлеге | 17 | 10,8% |
| 10 | Җир буенча сораулар | 10 | 6,4% |
| | **БАРЛЫГЫ** | **153** | **100%** |
| 11 | Уңай җавап бирелгән, гражданнар мөрәҗәгатьләре саны | 25 | 16,3% |
| 12 | Аңлатмалар бирелгән, гражданнар мөрәҗәгатьләре саны | 128 | 83,6% |
| | **БАРЛЫГЫ** | **153** | **100%** |

Гражданнар тарафыннан төзекләндерелгән торакка хокукны гамәлгә ашыру иң кискен һәм социаль әһәмиятле проблемаларның берсе булып кала. 2020 елның беренче ртыеллыгында торак мәсьәләләре өлеше 39,4% тәшкил итте (62 мөрәҗәгать).

Каты өслекле юлларны карап тоту, ремонтлау һәм төзү белән бәйле мөрәҗәгатьләр, автобус маршрутлары мәсьәләләре актуаль булып тора.

Халыкны социаль яклау Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты эшчәнлегенең мөһим аспекты булып тора. Социаль яклау

учреждениеләренең эше һәр конкрет кешегә максималь якын, аның проблемаларын хәл итүгә юнәлдерелгән. 2020 елның беренче яртыеллыгында Актаныш муниципаль районы Советына һәм Башкарма комитетына эшкә урнашу, ташламалар бирү, матди ярдәм күрсәтү мәсьәләләре белән бәйле 22 мөрәҗәгать (14%) керде.

Халык өчен уңайлы вакытта гражданнарны кабул итү графигы расланды. Муниципаль район Башлыгы, аның урынбасары, Башкарма комитет җитәкчесе, аның урынбасарлары, структур бүлекчәләр башлыклары гражданнарны шәхси кабул итә. Бердәм кабул итү көне — сишәмбе. Кирәкле документлар (шәхси кабул итү карточкалары яки кайбер бүлекчәләрдә журналлар) законнар нигезендә рәсмиләштерелә. Бүлек җитәкчеләре урынбасарлары кабул итүне сишәмбе көннәрендә генә түгел, кирәк булганда алдан язылмыйча да алып баралар. Гражданнарны күчмә кабул итүләр, район җитәкчеләренең халык белән даими очрашулары, «кайнар линия», муниципаль район Башлыгының интернет-кабул итү бүлмәсе эшли.

Кергән барлык мөрәҗәгатьләр контрольгә алынды. 16,3% (25) мөрәҗәгать уңай хәл ителде.

Азакта шуны билгеләп үтәсе килә, безнең уртак эшебезнең соңгы нәтиҗәсе- район халкына аларның мөһим проблемаларын хәл итүдә ярдәм итү. Һәм бу эшнең халыкның күңелендә аңлау һәм җавап табуы бик сөендерә. Районда үткәрелә торган чаралар халыкны битараф калдырмый. Җирле үзидарә органнарына тәнкыйть белән мөрәҗәгать итүчеләр саны арту белән беррәттән, рәхмәт сүзләре булган мөрәҗәгатьләр дә шактый килә.

Актаныш муниципаль районы
Башкарма комитетының
гомуми бүлек җитәкчесе Л.Г.Хәйдәрова